**Шәһәр күләмендә география фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың йомгаклау этабы биремнәре**
**2024-2025 уку елы**
**8 нче сыйныф**

**Эш вакыты – 120 минут**
**Гомуми балл – 92**

**1. Россия дәүләте белән гомуми чикләре булмаган илләр күрсәтелгән вариантны билгеләгез? (2 балл)**

а) Казахстан, Үзбәкстан  б) Кыргызстан, Молдова
в) Әрмәнстан, Беларуссь  г) Грузия, Болгария

**2. Бирелгән географик атамаларның кайсы артык? (2 балл)**

а) Урта Рус калкулыгы  б) Кольск ярымутравы  в) Онега күле
г) Ханка күле  д) Идел буе калкулыгы

**3. Әлеге файдалы казылма Мәскәү өлкәсендә табыла. Ул инде 1922 елдан бирле эшкәртелә. Бу чыганакның мәйданы 350 кв. км, ә руда запасы - 280 млн. тонна. Казылма байлыкны ачык ысул белән табалар.**
**Әлеге казылма байлык һәм аның чыганагы ничек атала? (4 балл)**

______________________________________________________________________

**4. Латин телендә әлеге табигый күренеш – кыру, кырып алу дип атала. Дулкыннар сулыкларның, тау токымнарын, яр буен, җимерәләр. Әлеге процесс ничек атала? (2 балл)**

а) Абиссаль  б) Абляция  в) Абразия  г) Абрис

**5. Сөйләнелә торган җир өсте рельефы Себергә хас. Җир өслеге аска таба иңгән урыннар берничә дистә метрдан алып берничә километрга кадәр була. Җәен аларда болын-дала үсемлекләре үсә. Алар күпъеллык туң катлам өлкәләрендә җир асты бозлары эрүдән хасил булалар.**
**Әлеге рельефны ничек атыйлар? (4 балл)**

______________________________________________________________________

**6. Табигый асылташны Урал тауларында һәм Саха-Якутия Республикасында табалар. Ул бик каты абразив материал буларак билгеле.**
**Әлеге минералны табып билгеләгез. (2 балл)**

а) Баллас  б) Алмаз  в) Карбонадо  г) Борт

**7. Әлеге түбәнлек Көнбатыш Себернең иң көньяк өлешендә урнашкан. Аның биеклеге диңгез өсте тигезлегеннән нибары 100-150 метр чамасы. Анда кечкенә каен урманнары, сазлыклар, күлләр бик күп. Үзе бер үк вакытта терлекчелек һәм игенчелек районы булып санала.**

**Әлеге түбәнлекне табып билгеләгез. (2 балл)**

а) Васюган б) Бараба в) Чулым г) Ишим

**8. Россиянең диңгезләрдән 700 км ераклыкта урнашкан диңгез порты бар. Ул материк эчендә бер зур елга буенда урнашкан. Зур диңгез суднолары әлеге елга буенча портка агымга каршы йөзеп керәләр.**

**Бу портны һәм елганы әйтеп бирегез. (4 балл)**

______________________________________________________________________

**9. Күпләргә таныш булган борынгы рус җыры “Шанлы дигез, изге Байкал” җырында мондый юллар бар:**

**...”Әй, Баргузин, тибрәндер дулкыннарны...”**

**Ни сәбәпле Баргузин сүзен җыр текстына керткәннәр. Ул нәрсәне аңлата? (6 балл)**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**10. Россиянең ике шәһәрендә телевизион манара төзергә уйлаганнар. Ике шәһәрнең диңгез өсте тигезлегеннән кайсысы югарырак, кайсысы түбәнрәк булуын ачыклаганнар. Шуларның берсе Улан-Уде булса, икенчесе-Диксон икән.**

**Сезнеңчә, кайсы шәһәр диңгез өсте тигезлегеннән югарырак, кайсы түбәнрәк урнашкан (4 балл)**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**11. Түбә өлешләре җимерелеп, йомырыланган калкулык, илебезнең Европа өлешендә урнашкан. Калкулыкның абсолют биеклеге 471 метрга җитә. Ул күп елгаларның субүләре булып 900 км га кадәр сузыла.**

**Бу калкулык ничек атала? Ул нинди өлкә һәм республика арасында урнашкан ? (4 балл)**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**12. Россиянең бер табигый зонасында күгелҗем яки күгелҗем-тутык төсендәге туфраклар өстенлек итә. Алар артык дымнан шулай барлыкка килгәннәр. Шул сәбәпле әлеге туфракларда үсемлекләр дә начар үсәләр.**

**Әлеге туфраклар кайсы табигый зонада урнашканнар һәм ул ничек атала? (4 балл)**

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

**13. Бирелгән тау исемнәрен, алар урнашкан территорияләр белән туры китереп, уклар ярдәмендә күрсәтегез: (4 балл)**

| | |
|---|---|
| 1. Приморье ягы | а) Бырранга |
| 2. Камчатка ярымутравы | б) Урта сырт |
| 3. Алтай Республикасы | в) Сихотэ-Алинь |
| 4. Таймыр ярымутравы | г) Алтай |

**14. Әлеге торак пунктының халык саны 3 меңнән 12 меңгә кадәр була. Шуларның 85% авыл хуҗалыгында эшли. Ул ничек атала? (2 балл)**

а) Шәһәр тибындагы поселок б) Станица
в) Кечкенә шәһәр г) Шәһәр

**15. Кайсы шәһәрдә җәен явым-төшем күп була? Ни өчен? (2 балл)**

а) Вологда б) Пермь в) Владивосток г) Волгоград

**16. Дөрес җавапларны билгеләгез? (6 балл)**

а) Терлекчелек зур күләмле продукция бирә
б) Ерымнар – җир өсте эрозиясе нәтиҗәсе
в) Арпа терлек азыгы буларак файдаланыла, үсү өчен яхшы сыйфатлы туфраклар таләп итә
г) Виноградчылык җир эшкәртү тармагына керә
д) Көнчыгыш Себер – болан асрауның төп районы

**17. Дөрес билгеләмәләрне күрсәтегез? (6 балл)**

а) Агросәнәгать – авыл хужалыгы, җиңел һәм азык-төлек сәнәгатеннән тора.
б) Урман полосалары белән кыр ышыклау – мелиорациянең бер тармагы булып санала.
в) Эре шәһәрләр тирәсендә дуңгызчылык тармагын үстерү отышлы.
г) Уҗым культуралары уңышы язгы чәчү культуралары уңышыннан түбән була.
д) Авыл хуҗалыгы тармагындагы яраксыз җирләрдә сарык үрчетү мөмкинлеге зур.

18. **Бик борынгы Гондвана материгы кайсы эраларда булган? (4 балл)**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

19. **Кырымдагы кайсы ләмле күлләр дәвалау сыйфатына ия булып торалар? (4 балл)**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

20. **Дымның парга әйләнүе һәм җиргә сеңүе явым-төшемгә караганда күбрәк булган климат ничек дип атала? (4 балл)**

______________________________________________________________________

21. **Россиядә көнбатыш җилләре ничек барлыкка килә һәм аларның әһәмияте нәрсәдә? (10 балл)**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

22. **Россиянең географик контурлы картасында никель табу чыганакларын шартлы билге – Ni – белән күрсәтегез. (10 балл)**

